МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.04.2023 Казан ш № 284

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4 маендагы 285 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4 маендагы 285 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш

белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 3 ноябрендәге 817 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 12 апрелендәге 284 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 4 маендагы 285 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.2 һәм 1.3.3 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килүче дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.5 пунктны көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гражданин эштән азат ителгән көнгә дәүләт вазыйфасын яки дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән яки аңа закон нигезендә үзгәртеп корылган яки юкка чыгарылган дәүләт органы функцияләре тапшырылган дәүләт органы (алга таба – дәүләт органы) катнаша.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү, гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша гамәлгә ашырылмый.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып пенсиягә өстәмә түләү (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында карар тора.

2.3.2. Кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында) җибәрелә.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Пенсиягә өстәмә түләү (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында карар реквизитлары:

пенсиягә өстәмә түләү (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта).

Пенсиягә өстәмә түләү (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

баш тарту турында карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

пенсиягә өстәмә түләү (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта).

Пенсиягә өстәмә түләү (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү һәм түләү турында мәгълүмат Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка почта аша яисә кулдан тапшырылган булса, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.2. Гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка электрон формада гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша тапшырылган булса, дәүләт хезмәте гаризаны һәм документларны Министрлыкта теркәгән көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көнлек срокта күрсәтелә.

2.4.3. Гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органына почта аша яисә кулдан тапшырылган булса, дәүләт хезмәте дәүләт органы тапшырган гаризаны һәм документларны Министрлык тарафыннан теркәгән көннән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.4. Гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органына электрон формада гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша тапшырылган булса, дәүләт хезмәте дәүләт органы тапшырган гаризаны һәм документларны Министрлыкта теркәгән көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көнлек срокта күрсәтелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү гражданинда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 календарь көненнән дә артмаска тиеш.

2.4.6. Мөрәҗәгать итүчегә пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң 10 календарь көн эчендә хәбәр ителә.

Пенсиягә өстәмә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрелгән мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсен шәхсән бирүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) (http://mtsz.tatar.ru) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге:

әлеге Регламентның 1.2 пунктында каралган тиешле граждан категорияләренә карауга бәйле рәвештә, әлеге Регламентның 2, 3, 4, 5 нче кушымталарында китерелгән формаларның берсе буенча гариза;

шәхесен, яшен, яшәгән урынын, кайсы гражданлыкка караганлыгын таныклый торган документ күчермәсе;

яшәү урыны буенча Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының территориаль органы тарафыннан бирелә торган, картлык буенча вакытыннан алда иминият пенсиясе билгеләү яки инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләү өчен документлар белән гариза кабул итү турында белдерү күчермәсе, – «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясының 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче пенсия билгеләнгән очракта;

хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66, $66^1$ статьяларында билгеләнгән тәртиптә алынган, хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар) турындагы белешмәләрнең күчермәсе;

хәрби билет күчермәсе (хәрби хезмәт үткән кешеләр өчен).

Гражданин гаризага Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен үтәве турында белешмә формасын һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен үтәве турында салым органы белешмәсен теркәргә хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органнан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон

формада да, һәм әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучы зат мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.6.2. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле органнардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.6.3. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа теркәлгән документларның күчермәләре (шәхесне раслаучы документ күчермәсеннән тыш) нотариаль рәвештә расланырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларның күчермәләрен шәхсән тапшырган очракта, әгәр документлар күчермәләре нотариаль рәвештә расланмаган булса, алар оригиналларын күрсәтеп тапшырыла.

2.6.4. Гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар, шулай ук электрон документлар формасында җибәрелә (тәкъдим ителә) ала. Электрон документлар формасында тапшырыла торган гаризалар һәм документлар «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп электрон имза белән имзалана һәм электрон чыганакларны һәм (яки) гомуми кулланыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән Интернет челтәрен кулланып тәкъдим ителә.

Гаризаны электрон документлар формасында җибәргәндә, аңа теркәлгән документларның күчермәләре (шәхесне раслаучы документ күчермәсеннән тыш) нотариаль рәвештә расланырга тиеш.

2.6.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.6. Гариза, шул исәптән электрон документ формасындагысы да, әлеге Реламентның 2.6.8 пунктында каралган очраклардан тыш, эштән азат ителгән көнне гражданин дәүләт вазыйфасын яки дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органына тапшырыла.

2.6.7. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле оешмалардан түбәндәге документлар һәм белешмәләр алына:

дәүләт граждан хезмәткәренең дәүләт хезмәткәре биләгән соңгы вазыйфа буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына

кертелүе турында (1997 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментыннан;

2016 елның 1 гыйнварыннан дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен биләнгән соңгы вазыйфаның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына кертелүе турында – «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан;

дәүләт вазыйфасыннан, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан азат итү турындагы карарның күчермәсе – дәүләт органының (Министрлыкның) структур бүлекчәсеннән (дәүләт (муниципаль) архивы);

айлык акчалата бүләкләү (акчалата тәэмин итү) турында белешмә (белешмә формасы Министрлык тарафыннан раслана һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла) – дәүләт органының (Министрлыкның) структур бүлекчәсеннән (дәүләт (муниципаль) архивы);

дәүләт граждан хезмәтенең аерым шартлары өчен вазыйфа окладына өстәмә түләү билгеләү турында боерык күчермәсе (2006 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 мартына кадәр дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – дәүләт органының (Министрлыкның) структур бүлекчәсеннән (дәүләт (муниципаль) архивы);

дәүләт сере өчен вазыйфаи окладка өстәмә түләү билгеләү турында боерык күчермәсе (2005 елның 31 декабренә кадәр дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – дәүләт органының (Министрлыкның) структур бүлекчәсеннән (дәүләт (муниципаль) архивы);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы (булмавы) турында (Федераль салым хезмәтеннән);

шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

гражданның хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы турында (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорлар өчен) – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге пунктта каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.6.8. Гариза бирелгән көнгә дәүләт органы үзгәртеп корылган яки бетерелгән очракта, ул үзгәртеп корылган яки бетерелгән дәүләт органы функцияләре Татарстан Республикасы законнары нигезендә тапшырылган дәүләт органына бирелә.

Әлеге дәүләт органы булмаганда, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны (документларның күчермәләрен) теркәп, гариза Министрлыкка тапшырыла.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

документларның күчермәләре нотариаль рәвештә расланмаган очракта, документлар исемлегеннән оригиналларны тәкъдим итмәү – шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта (электрон почта) аша нотариаль рәвештә расланмаган документларның күчермәләрен җибәрү;

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;

гариза һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә электрон имза белән имзаланмаган электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.

2.7.2. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы сайтында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы;

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15, 16 статьяларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 мартындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45, 46 статьяларында билгеләнгән шартларның үтәлмәве;

гражданинның Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләнергә тиешле, пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү өчен мөрәҗәгать итү көненнән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган бурычлары булуы.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты һәм тәртибе турындагы

мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.8.3. Гражданинның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм документлар Министрлыкка алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.3. Әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар почта юлламасы яки электрон документ (документлар пакеты) рәвешендә Министрлыкның эш сәгате тәмамланганнан соң килсә, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала. Әгәр гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) ял яки бәйрәм көнендә алынса, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре

белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан ярдәм күрсәтү;

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гаризаны һәм документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкта алынырга мөмкин.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гражданин вазыйфа биләгән органның кадрлар хезмәтенә гаризалар бирү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә башкарыла.

2.14.2. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар дәүләт органына (Министрлыкка), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон чыганаклардан файдаланып та дәүләт органына (Министрлыкка) тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гаризага 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары нигезендә гади электрон имза куелырга тиеш.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.4. Министрлыкка кабул итүгә мөрәҗәгать итүчеләрне язу (алга таба – язу) Министрлыкның телефон номеры буенча телефон элемтәсе аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкта билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Телефон элемтәсе аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

(фамилиясе, исемен һәм атасының исемен (булган очракта))

телефон номеры;

электрон почта адресы (ихтыяры буенча);

кабул итү көннәре, вакыты һәм урыннары.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Телефон элемтәсе аша алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның телефон номеры буенча билгеләнгән сәгатьләрдә телефон элемтәсе аша алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән кабул итү максатын күрсәтүдән тыш башка гамәлләр башкаруны, шулай ук кабул итү өчен броньланырга тиешле вакыт аралыгының озынлыгын исәпләү өчен кирәкле мәгълүмат бирүне таләп итү тыела.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Дәүләт пенсияләре» программа продукты.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.7. Дәүләт хезмәте КФҮ аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы аша электрон рәвештә күрсәтелми.»;

3 бүлектә:

3 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары»;

3.1.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хатаны төзәтү»;

3.3.1 пунктының беренче абзацында «2.5» саннарын «2.6.1» саннарына алмаштырырга;

3.3.2 пунктның җиденче абзацында «кергәндә теркәлгән номеры» сүзләреннән соң «, җитешми торган документларның исемлеге һәм аларны тапшыру сроклары» сүзләрен өстәргә.

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Министрлыкта теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Дәүләт органы гариза биргән көнгә үзгәртеп оештырылган яисә бетерелгән очракта яисә законнар нигезендә гражданин дәүләт вазыйфасын биләгән яисә эштән азат ителгән көнгә дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән, үзгәртеп корылган дәүләт органы функцияле Министрлыкка тапшырылган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда Министрлык белгече, шул исәптән электрон рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә һәм түбәндәгеләрне ала:

дәүләт граждан хезмәткәренең дәүләт хезмәткәре биләгән соңгы вазыйфа буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына кертелүе турында белешмәләр (1997 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментыннан;

2016 елның 1 гыйнварыннан дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен биләнгән соңгы вазыйфаның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына кертелүе турында белешмәләр– «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан;

хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66, 66[1] статьяларында билгеләнгән тәртиптә алынган, хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар) турындагы белешмәләрнең күчермәсен – дәүләт (муниципаль) архивыннан;

гражданинның хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы турында белешмәләр һәм хезмәт кенәгәсе күчермәсен (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорлар өчен) – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

дәүләт вазыйфасыннан, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан җибәрү турындагы карар күчермәсен – дәүләт (муниципаль) архивыннан;

айлык акчалата бүләкләү (акчалата тәэмин итү) турында белешмә (белешмә формасы Министрлык тарафыннанраслана һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла) – дәүләт (муниципаль) архивыннан;

дәүләт граждан хезмәтенең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсен (2006 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 мартына кадәр дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – – дәүләт (муниципаль) архивыннан;

дәүләт сере өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсен (2005 елның 31 декабренә кадәр дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – дәүләт (муниципаль) архивыннан;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы (булмавы) турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтеннән;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

Министрлык белгече «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап дәүләт граждан хезмәткәре биләгән вазыйфа буенча дәүләт граждан хезмәткәрен Реестрга кертү турында белешмәләр ала.

Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булуы (булмавы турында) белешмәләр бирмәгән булса, Министрлык белгече ведомствоара гаризалар нигезендә, шул исәптән электрон рәвештә, ведомствоара электрон багланышларның региональ системасын кулланып, югарыда күрсәтелгән белешмәләрне соратып ала.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында гаризалар һәм алынган нәтиҗәләр, шул исәптән региональ ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан да.

3.4.3. Әгәр гражданин эштән азат ителгән көнне Министрлыкта дәүләт вазыйфасын яки дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән булса, Министрлык белгече Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон

Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше системасын куллану юлы белән түбәндәгеләрне сората һәм ала:

дәүләт граждан хезмәткәренең дәүләт хезмәткәре биләгән соңгы вазыйфа буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына кертелүе турында белешмәләр (1997 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментыннан;

2016 елның 1 гыйнварыннан дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен биләнгән соңгы вазыйфаның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына кертелүе турында белешмәләр– «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан;

хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66, $66^1$ статьяларында билгеләнгән тәртиптә алынган, хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар) турындагы белешмәләрнең күчермәсен – Министрлык аппаратының структур бүлекчәсеннән;

гражданинның хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы турында белешмәләр һәм хезмәт кенәгәсе күчермәсен (2020 елның 1 гыйнварыннан башланган чорлар өчен) – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

дәүләт вазыйфасыннан, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан җибәрү турындагы карар күчермәсен – Министрлык аппаратының структур бүлекчәсеннән;

айлык акчалата бүләкләү (акчалата тәэмин итү) турында белешмә (белешмә формасы Министрлык тарафыннан раслана һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла) – Министрлык аппаратының структур бүлекчәсеннән;

дәүләт граждан хезмәтенең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсен (2006 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 мартына кадәр дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – Министрлык аппаратының структур бүлекчәсеннән;

дәүләт сере өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсен (2005 елның 31 декабренә кадәр дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – Министрлык аппаратының структур бүлекчәсеннән;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы (булмавы) турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтеннән;

шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булуы (булмавы турында) белешмәләр бирмәгән булса, Министрлык белгече ведомствоара

гаризалар нигезендә, шул исәптән электрон рәвештә, ведомствоара электрон багланышларның региональ системасын кулланып, югарыда күрсәтелгән белешмәләрне соратып ала.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Министрлык гаризаны теркәгән көннән алып җиде календарь көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында гаризалар һәм алынган нәтиҗәләр, шул исәптән региональ ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан да.

3.4.4. Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

3.4.5. Әлеге Регламентның 2.6.7 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

3.4.7. Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.5.1, 3.5.2 пунктларда «министр (министр урынбасары)» сүзләрен тиешле саннарда һәм килешләрдә «министр (аның бурычларын үтәүче зат)» сүзләре белән алыштырырга;

3.5.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Министрлык белгече әлеге Регламентның 3.4.2 һәм 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар, шулай ук мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

3.5.1 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3.5.3 пунктның өченче абзацында «биш эш» сүзләрен «җиде календарь» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.4 пунктның икенче абзацында «2.5» саннарын «2.6» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хатаны төзәтү»;

4 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламент үтәлешен тикшереп тору формалары»;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрның белешмә телефоннары һәм Министрлык тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган Министрлыкның вазыйфаи затлары турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла»;

5.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда.»;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.